**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Березняк авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**2022 елның 10 октябре** **№ 4**

**Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын үткәрүне билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2022 елның 22 октябренә 13 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

2. 2022 елның 22 октябренә 14 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

3. 2022 елның 22 октябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

4. 2022 елның 22 октябренә 16 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Березняк авыл җирлегенең Березняк авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Березняк авылы, Ленин урамы, 17 йорт адресы буенча урнашкан авыл Мәдәният йорты бинасында үткәрергә.

5. «Сез 2023 елда Кукмара муниципаль районының Березняк авыл җирлеге Березняк авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 80 яшькә житкән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә

үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Березняк авылының Гагарин, Яр буе урамнарында су агызу торбалары урнаштыру (сатып алу, кайтару, урнаштыру, шартнамә буенча эшләргә түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- Березняк авылы юлларын кардан чистарту (шартнамә буенча эшләр өчен түләү, ягулык һәм майлау материаллары сатып алу, хезмәткәргә хезмәт хакы түләү).
- Березняк авылы зиратында агачларын кисү (эшләргә шартнамә буенча түләү); проект-смета документлары һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру;
- -янгын гидрантларын, су алу колонкаларын һәм аларны комплектлау җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру (материал сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;»

«РИЗА» «КАРШЫ»

6. Гражданнар җыенын үткәрү өчен, торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча бүләргә.

7. Березняк авыл җирлеге Башкарма комитетын гражданнар җыенын үткәрүгә җаваплы итеп билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Березняк авыл җирлеге башлыгы Р.Ф. Шәрипов